

Кешелекле, мәрхәмәтле, сабыр булу, кешеләргә авыр чакларда ярдәмгә килv - һәркемгә дә кирәк сыйфатлардыр, минемчә. Шулай ук, тvземлелек, хезмәт соючәнлек кешенен кешелеклелеген дә, дәрәжәсен дә арттыра. Олы буын кешеләре белән горурланырга гына кала, чонки алар авырган чакта да, тvземле генә табигатьнен койсезлегенә юрый. Язмамнын сәбәбе дә нәкъ шундый кеше белән таныштыру. Ул Раисә Мәзит кызы Манюрова – Кочкурово районы Татар Ымызы авылында гомер итvче тырыш хезмәткәр һәм сигез бала тәрбияләгән Ана.
Тормышында нәрсәләр генә булып vтмәгән язма героебызнын. Ул:
- 1942 елда мина ун яшь иде, апамнын баласын карарга Мәскәvгә киттем. Ә Муртазаны, булачак иремне, Боек Ватан сугышы тәмамлангач, армиягә хезмәткә алдылар. Аннан кайткач, каенсенелем мине ана бик тә мактагач, минем артымнан Мәскәvгә килеп алды. Шулай туган Татар Ымызыма кайттым.  Бу 1952 ел иде.      Шул елны Муртаза белән Раисәнен гаилә бәйрәме – туйлары vтә. Бергә яшәvнен икенче елында яшь гаилә vз йортларын този. Аннары шул йортта, мәхәббәт эчендә сигез бала – Румия, Роза, Фатыйма, Нуржихан, Халидә, Сания, Рифкат, Рашид туа. Алар тиешле тәрбия алып vсәләр. Әти-әниләре, балаларын кирәк-ярак белән тәэмин итv очен, зур хужалык белән яши: авылда топ ашатучы – сыерлары булган, егермегә кадәр сарык асраганнар, каз – vрдәк – тавыклар vрчеткәннәр. Шулай балаларын vстергәннәр, белем биргәннәр. Тик Раисә Мәзит кызынын жаны  тыныч тvгел, кайгысы картайта аны: «Тышта 1970 ел иде. Олы кызым, Румиямнен Саранскта укыган чагы. Фажигале рәвештә вафат булганда ана бит унсигез генә яшь иде, - дип йорәге озгәләнеп искә ала Раисә Мязитовна. – Бик авыр булды кичерvләре. Ә 2013 елда тормыш иптәшем, гомере буе туган авылыбыздагы «Красная заря» колхозында механизатор булып эшләгән Муртаза Мәзит улы, бакыйлыкка кvчте. Анын белән икәv 61 ел дус һәм бәхетле гомер иттек бит».
Әйе, жир йозенә кеше хезмәт итәргә килә. Кешене кеше итvче дә, яшәвенә мәгънә, коч бирvче дә хезмәт. Һонәри тырышлык, тәжрибәдән башка унышларга ирешv дә момкин тvгел. Тик торырга яратмаган Раисә Мәзитовна гомер буе шәхси эшмәкәр булып хезмәт итә. Эштән бераз вакыты бушаганда, Раисә апа балаларына торле киемнәр бәйли, кvлмәк-фартуклар тегә; бер лоскут материал да тикмәгә ятмый. Анын һәр кул эше бер-берсенә ошамаган: vзенчә фасон, vзенчә бизәк ясап матурлый торган була. Балаларына, оныклары белән бергә, кvршеләренә, дусларына, туганнарына бvләк итеп биреп жибәрә кул эшләрен Мәзит кызы Раисә.
Бvген шулай донья бара. Бер-бер артлы балалар vсеп ояларыннан очып китә. Алар

Мәскәүдә үз гаиләләре белән матур гына яшиләр. Раисә апа Манюрова яшерми: балаларын тәрбияләп үстерү җиңел булмаган, әмма  тормыш иптәше белән бергә, аларга тиешле тәрбия һәм белем биреп кеше итә алулары йөрәгенә тынычлык урнаштыра. Юкка гына әйтмиләр: ана бәхете  - балаларында. Бүген унике оныгы, унбиш оныкчыгы (правнук) уңышларына шатлана язма героебыз, алар – яшәвенең мәгънәсе, шатлыгы һәм горурлыгы. Рәисә апаның өендә рәхәт һәм ул бик тә кунакчыл.
Язма героебызның өлешенә бәхет тә, авыклыклар да җитәрлек тошкән. Раисә Мәзит кызы Манюрова Бөек Ватан сугышының михнәтле балачагын халкы белән бергә үткәрә, анда югалткан туганнары кайгысын кичерә, кыне-тыне эшли, әмма язмышны тиешенчә кабул итә; сынмый, сыгылмый, сигез бала асраган батыр Ана булып яши белә. Ул бәхетле, чөнки картлыгын туганнары, дуслары хөрмәтендә каршылый һәм барчасына изге теләктә ул: һәрвакыт исән-имин булып, алдагы көннәрендә шатлык, уңышлар һәм рәхәт тормыш кына көтсен аларны.

**Наилә Насырова**